РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 сентябрь 2022ел №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Туйкә авылының Совет ур. 1 йорттан 41 йортка кадәр, Крайняя ур. 1 йорттан 8 йортка кадәр, Яшьләр ур. 1 йорттан 20 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен, 2022 елның 07 октябрендә 10 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Туйкә авылының Гагарин ур. 1 йорттан 18 йортка кадәр, Җәлил ур. 1 йорттан 17 йортка кадәр, Киров ур. 1 йорттан 28 йортка кадәр, Ленин ур. 1 йортткан 21 йортк акадәр, Үзәк ур. 1 йорттан 7 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен, 2022 елның 07 октябрендә 13 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Туйкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 07 октябрь 2022 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 07 октябрь 2022 ел 13. 00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Туйкә авылы, Гагарин ур., 4А йорт, Туйкә авылы мәдәният йорты залы;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2022 елның 27 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түйкә авылы, Җәлил урамы,19 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Түйкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Түйкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Җирләү урыннарын карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар алу) Туйкә авылы;
- Туйкә авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү).;
- Туйкәдә тракторчыга карны механикалаштырып җыю буенча хезмәтләр өчен түләү (чит оешмаларның юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләре);;
- Туйкә авылы территориясендә үлән чабу (килешү буенча эш өчен түләү);
- халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчәргә яраклы суны биохимик һәм бактериологик анализлауны үткәрү, килешү буенча эшләр өчен түләү) Туйкә авылында;
- Туйкә авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «авыл бәйрәме», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);
- Трактор өчен җиһазлар һәм запас частьләр сатып алу (өем,төягеч, чапкыч).

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар җуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл, Ленин ур., тукталыш янында;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында;

7. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис Р.Р.Закирова